УДК 821.512.145

***Р.Ф. Харрасова***

# ФӘНГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

*(Галимҗан Нигъмәтинең тууына 120 ел)*

В статье рассмотрены основные вехи жизни и творчества профессора Галимджана Амирджановича Нигмати (1897–1941), литературоведа, литературного критика, внесшего большой вклад в развитие комплексного изучения татарского художественного творчества.

**Ключевые слова:** Галимджан Нигмати, татарское литературоведение, татарская литературная критика, комплексное изучение художественного творчества.

Узган гасырның иң шомлы елларында үз халкына мәгърифәт-фән өлкәсендә хезмәт күрсәткән, бай гыйльми мирас калдырган, егерменче-утызынчы еллар әдәбият белемен, тәнкыйтен аның исеменнән башка күзаллап та булмаган шәхесләрнең берсе, һичшиксез – Галимҗан Нигъмәти. Галимнең гыйльми-теоретик карашлары, әдәби хәрәкәттәге теге яки бу күренешләргә мөнәсәбәте милли сүз сәнгатебезнең узган чорлардагы барышын аңлауда мөһимлеген югалтмаган күләмле хезмәтләрендә, әдәбият белеменең теоретик нигезләрен ачкан китапларында, аерым каләм ияләренә һәм әдәбиятка җитди тәэсир ясаган язмаларында саклана.

* * *

Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәтуллин 1897 елның 26 июлендә Башкортстан туфрагында – Чишмә (Благовар) районы Үдрәкбаш (Өйдерәкбаш) авылында дөньяга килә. Россия авылларын әледән-әле көчәеп алган ачлык интектергән, кешеләрнең, нигезләрен ташлап, күпләп шәһәргә күченгән гасыр азагы бу. Үтә ярлы крестьян Әмирҗан аганың гаиләсе дә 1899 елда Уфага китеп бара. Һәм монда ата кеше, икътисади авырлык чылбырын өзү өчен, бар көчен улын укытуга куя, 1911 елда Галимҗанны дини белем янәшәсендә гимназия курсы буенча дөньяви предметлар да кергән «Галия» мәдрәсәсенә илтә. Ул анда 1917 елгача белем ала. Бүгенге көн галимнәре, әлеге уку йорты заманына күрә милли институт дәрәҗәсендә булган, дигән караштa тора. Монда Казан, Мәскәү, Багдад, Каһирә кебек шәһәрләрнең һәм Төркиянең югары уку йортларын, Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган зур белгечләр белем биргән. Г. Ибраһимов – әдәбият, Ә. Вәлиди – фәлсәфә, Г. Терегулов – психология, З. Кадыйри – гарәп, төрек телләре, Ф. Сәйфи-Казанлы – тарих, Г. Шинаси – педагогика, методика кебек фәннәрне укыткан. Г. Нигъмәти соңгы сыйныфларда үзе дә мөгаллимлек итә башлаган.

Г. Нигъмәтинең Октябрь инкыйлабына кадәрге төп хезмә-

те – балаларга белем бирү булса, аннан соң ул аны иҗтимагый эшчәнлек белән бәйли: шәкертләрне мәдәни агарту эшләре белән шөгыльләнә, «Парлак» кулъязма әдәби журналына мөхәррирлек итә. Г. Нигъмәтинең чын мәгънәсендәге журналистлык юлы исә 1918 ел азагында башлана. Иң башта ул Көнчыгыш фронт газетасы «Кызыл яу»га әдәби хезмәткәр булып урнаша. 1919 елның язында, Колчак гаскәрләренең көчле һөҗүменә каршы тора алмыйча, Кызыл Армия Уфадан чигенгәндә, Г. Нигъмәти Бәләбәйгә күченә һәм шулай ук редакциягә эшкә керә. Ул бераздан Коммунистлар партиясенә кабул ителә. 1919 елның ахырында, Бишенче Армиянең Революцион хәрби шурасы карары белән, газета хезмәткәрләре партия Үзәк Комитетының Себер бюросы карамагына күчерелә. Шуның нәтиҗәсендә, Г. Нигъмәти Омскида (бераздан – Новосибирскида) чыккан «Азат Себер» газетасының башта җаваплы сәркатибе, аннан мөхәррире вазифаларын башкара, партиянең губерна комитетында инструктор булып та эшли.

1921 елда Г. Нигъмәти Себердән Мәскәүгә күченә һәм Көнчыгыш коммунистик институттагы берьеллык курсларда укый, татар курсантларына әдәбият дәресләре дә бирә. Курсларны тәмамлаганнан соң, булачак галим Дәүләт журналистика институтына укырга керә, ләкин тиздән укуын ташлый, чөнки аны 1923 елда Үзәк башкарма комитет аппаратына милли матбугат инструкторы итеп билгелиләр. Г. Нигъмәти Мәскәү чорында журналистика, әдәби тәнкыйть, бигрәк тә иҗтимагый фәннәр өлкәсендә ныклап таныла башлый. Ул, киң катлам халыкка адреслап, марксизм-ленинизм тәгълиматы, социализм нигезләре турында гыйльми хезмәтләр, мәдәният, әдәбият, матбугат проблемаларын чагылдырган мәкаләләр, китаплар яза.

1926 елның ахырында Г. Нигъмәтине партия Үзәк Комитеты «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының баш мөхәррире сыйфатында Казанга җибәрә. Ул 1928–1929 елларда – Татарстан дәүләт китап нәшриятының баш мөхәррире вазифасында, аннан соң ике ел «Яңалиф» журналының җаваплы мөхәррире булып эшли, шуның янәшәсендә, берара Марксизм-ленинизм институтында әдәбият секциясенә җитәкчелек итә. Галим 1929–1933 елларда – Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, 1935–1937 елларда – шул ук кафедраның мөдире, ә 1934 елдан – инде профессоры да. Г. Нигъмәти утызынчы еллар башына күренекле тәнкыйтьче буларак танылa. Ике унъеллык чигендә ул 4 күләмле китап, Дәрдемәнд, М. Гафури, Г. Коләхмәтов, Ш. Бабич, Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, Һ. Такташ һәм башкаларның зур иҗатларына кагылышлы иллегә якын мәкалә бастыра, татарлар арасында рус классикасын пропагандалау белән шөгыльләнә. Г. Нигъмәтинең утызынчы еллар язмаларында иҗат методлары, әдәби-мәдәни барыш мәсьәләләре, әдәбият

гыйльменең үсеш юнәлешләре, әдәбиятның сыйфатлылыгы кебек үз заманы өчен үтә дә актуаль проблемалар күтәрелә.

Г. Нигъмәти әдәбият белеме өлкәсенә күпсанлы галимнәр әзерләп калдыра. Ул М. Гайнуллин, Х. Ярми, Г. Халит, Җ. Вәзиева, Я. Агишев, Г. Кашшаф һәм башка танылган шәхесләрнең остазы иде. Кызганыч ки, галимнең педагоглык һәм фәнни эшчәнлеге иртә өзелә: Г. Нигъмәти шәхес культы елларының репрессияләренә эләгә. Аны 1937 елның 16 сентябрендә, троцкийчы контрреволюцион оешма әгъзасы дип гаепләп, кулга алалар, һәм 1940 елның 17 гыйнварында, 5 елга хөкем итеп, Устьвымлаг лагерена җибәрәләр. Сәламәтлеге какшаган Г. Нигъмәти 1941 елның 4 декабрендә вафат була.

* * *

Татар тәнкыйте инкыйлабтан соң Яңа заман сүз сәнгате нинди булырга тиешлек соравына җавап эзли. Сәнгатькә кагылышлы элекке карашлар кризис кичергән бу чорда теләсә кайсы тәнкыйтьче рухи кыйммәтләрне яңадан бәяләргә омтыла, үткәндәге күзаллаулары искердеме, әллә яшәргә хаклымы, зур һәм кече әдәби берәмлекләрне нинди яңа алым-чаралар яисә чит фәнни өлкәләрдәге табышлар ярдәмендә анализларга мөмкин дип уйлана. Моны егерменчеутызынчы елларда актив язган теләсә кайсы тәнкыйтьче мирасы ярдәмендә дәлилләргә мөмкиндер. Әйтик, Г. Нигъмәтинең 1931 елда дөнья күргән «Әдәбият һәм тормыш» хезмәтендә шундый бүлекләр бар: «Әдәбият фәнендә формалистлык-буржуа карашы», «Әдәбият фәнендә психологик карашлар». Ул шулай ук бу елларда «Иске әдәби мирастан файдаланырга кирәкме?» (1928), «Әдәби тәнкыйтьтә механистик һәм эклектик бозуларга каршы» (1931) һ.б. мәкаләләр дә иҗат итә, алар аша фәндә һәм әдәбиятта барган күренешләргә мөнәсәбәтен белдерә.

Әдәбиятның инкыйлабтан соңгы яңарышы, анда яңа агымнар, мәктәпләр барлыкка килү сәнгатьнең иҗтимагый-социаль тормыш белән ни дәрәҗәдә тыгыз бәйләнгәнлеген ачык күрсәтеп тора башлый, шул сәбәпле әдәбият белгечләре дә иҗтимагый мәсьәләләрне читләп уза алмый. Инкыйлабны көтеп алган яшь галим иң башта, үзенең остазы Г. Ибраһимов кебек үк, вакытлы матбугатта актив рәвештә татар тормышына, аның төрле институтларына, бигрәк тә мәдәният-сәнгатькә, шул исәптән әдәбиятка Октябрь алып килгән күренешләрне, марксизм-ленинизм тәгълиматын ачарга, уңай яктан бәяләргә һәм пропагандаларга керешә. Г. Нигъмәтинең егерменче еллар башында басылган «Карл Маркс безгә нәрсәләр калдырды?» (1922), «Ленин һәм пролетариат революциясе» (1924), «Адәмнәр ничек яратылган?» (1924) мәкаләләре, «Коммунизм турында» (1924) китабы киң катлам халыкка сәяси һәм фәнни мәгълүмат җиткерүне максат итә, ә инде унъеллык ахырындагы «Февраль ничек хәзерләнде» (1928), «Партиянең уникенче съезды һәм милләт-

ләр мәсьәләсе» (1928) язмалары егерменче гасыр башында иҗтимагый-сәяси барыштагы хәлләрне чагылдыручы хезмәтләр булып тора.

Г. Нигъмәти мәкаләләренең идея-тематик юнәлеше башкарган вазифалары белән дә билгеләнә дип уйларга кирәк. Әйтик, партиянең төп газеталарыннан булган «Кызыл Татарстан»га баш мөхәррир итеп билгеләнү үзе үк аның алдына көнүзәк мәсьәләләрне яктырту һәм инде бигрәк тә партия күзлегеннән бәя бирү таләбен куя. Галимнең егерменче еллардагы әдәби барышка мөнәсәбәтле «Октябрь һәм әдәбият» (1922), «Әдәбият мәйданында» (1925) исемле хезмәтләре дә – илкүләм иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрнең сүз сәнгатенә йогынтысын уңай бәяләү рухында. Ул аларда инкыйлабтан соңгы татар әдәбиятына күзәтү ясый, иҗат методы мәсьәләләренә туктала, реализм белән романтизм янәшәсендә, заманга бәйле популярлашып киткән символизм, футуризм, имажинизм кебек төшенчәләрне һәм күренешләрне дә аңлатып уза.

Г. Нигъмәти хезмәтләренең атамалары аның инкыйлаби барышта торткан тарафын – «кызыл» пропагандистлыгын сөйли. Алай гына да түгел, «Сәнгать һәм әдәбият турында Маркс һәм Энгельс» дигән хезмәтендә Г. Нигъмәти партиячел тенденциялелекне ачыктан-ачык яклап чыга. Бу чорда тәнкыйтьче, бер яктан, әдәбиятны «дәүләтиләштерү», партия күзәтчелеге астына кертү өчен көрәшүчеләргә, бигрәк тә Г. Ибраһимовка, икенче яктан, әдәбиятка кагылышлы язмалар да калдырган атаклы рус марксизм-ленинизм теоретикларына таяна. Г. Нигъмәти хезмәтләрендә В. Ленин, Г. Плеханов, А. Луначарский, Л. Троцкий һәм башка большевик тәнкыйтьчеләрнең, идеологларның партиягә җаны-тәне белән хезмәт иткән М. Горький кебек әдипләрнеке белән кисешкән нокталарны табу авыр түгел. Л. Троцкийның Г. Нигъмәтинекенә аваздаш исемдәге «Литература и революция» китабы 1923 елда дөнья күрсә дә, аның инде шул рухтагы мәкаләләре 1907–1923 еллар аралыгында язылган була. Әлеге хезмәт руларның гына түгел, татарларның да инкыйлабтан соңгы әдәбият турындагы карашлары һәм тәнкыйть терминологиясе формалашуга зур йогынты ясый. Г. Нигъмәти чор әйләнешкә кертән һәм алга таба актив кулланылырга тиешле дип фаразланган иҗтимагый-сәяси терминнарны халыкка аңлату максатыннан басылган «Сәяси лөгать» (1925) сүзлеген төзүдә катнаша. Димәк, эш барышында ул турыдан-туры Л. Троцкий һәм башка марксистларның язмаларына, Г. Ибраһимов кебек, татар тәнкыйтендә яңа терминнарны активлаштырган каләм ияләренең иҗтимагый-сәяси эчтәлектәге хезмәтләренә мөрәҗәгать иткән дип уйларга кирәк.

Г. Сәгъди 1927 елда ук инде «Безнең юл» журналында: «Диалектик материализм, марксизм нигезендә ныклыгы белән үзен тиз вакыт эчендә танытып өлгерүче Г. Нигъмәти булды», – дип яза (№ 10, б. 41). Г. Ибраһимов та аны «әдәбиятны-сәнгатьне

марксизм-ленинизм буенча тикшерүче, тәнкыйть кыйлучы»лар арасында атый [Ибраһимов, б. 504]. Дөрес, галим төрле партия эшлеклеләренең хезмәтләренә таянса да, заманга ияреп, тенденциозлыкка бирешсә дә, таптапталган юллардан гына атлаучы, фәнгә һәм әдәбиятка сәяси корал дип кенә караучы түгел. Чын мәгънәсендә академик фән кешесе саналган Г. Нигъмәти каләменә – филологик тирәнлек, ә үзенә эстетик күзаллауларны калыплаштыру омтылышы хас. Ул әдәбиятка бервакытта да социологик планда гына якын килмәде, әдәби әсәрләр эчтәлеген бары тик коммунистларга файдалы сәяси яссылыктан гына бәяләмәде, чөнки Г. Нигъмәти сәнгатиэстетик сыйфатламаларны тәмам читкә кую тарафдары түгел иде. Моның шулай икәнлеген галимнең: «Революциягә килгән һәм аның эчендә пешеп чыккан әдипшагыйрьләребезнең бурычлары исә, чын революция рухы белән сугарылган, художество ягыннан эшләнгән, эшче-крестьянның киң катлавы аңларлык рәвештә простой булган, простойлыгы белән матур булган сәнгать әсәрләре бирүләреннән гыйбарәт булырга тиеш» [Нигъмәти, 1929, б. 28], – дип язып чыгуы да күрсәтә. Без бүген, узган чорларга әйләнеп карап, галимнәр арасыннан әдәбиятны өйрәнүдә вульгар социологизм агымына бөтенләй бирешмәүчеләрне таба алмабыз, чөнки социалистик җәмгыять төзү идеясенә илкүләм бирелү, шуңа хезмәт итмәгән әсәрләр дөнья күрергә тиеш түгел дип ышану, ә хезмәт иткәннәрен пропагандаларга омтылыш үзеннәнүзе сүз сәнгатен сыйнфый позицияләрдән торып бәяләүгә китерә. Димәк, Г. Нигъмәтинең дә, әдәби барышны өйрәнгәндә, марксист каләм ияләре язганнарга табынуы табигый.

Г. Нигъмәти тәнкыйть белән ныклап егерменче еллар ахырында шөгыльләнә башлый: әдәби барышка күзәтүләр ясый, рецензияләр, юбилей материаллары яза, теге яки бу каләм иясенең әсәрләрен гыйльми проблема яссылыкларында тикшерә. Утызынчы елларга кергәч, галим татар классиклары иҗатын өйрәнүне тагын да көчәйтә, иҗат портретлары тудыру белән шөгыльләнә, әдәбият гыйльменең үсеш юллары, совет чоры сүз сәнгатендә килеп туган күренешләр турында ныклабрак уйлана.

Г. Нигъмәти, 1927 елда «Ун ел эчендә безнең әдәбиятыбыз» дигән мәкалә язып, татар әдәбиятының инкыйлабтан соңгы барышын ачып сала. Соңрак әлеге мәкалә форматы бераз үзгәргән рәвештә «Революция елларындагы әдәбиятыбыз» (1929) җыентыгында дөнья күрә. Анда сүз милли әдәбиятыбызның инкыйлабкача хәле, әдипләребезнең илкүләм сәяси-иҗтимагый үзгәрешләргә мөнәсәбәте, әлеге үзгәрешләрнең алар каләменә һәм рухиятенә тәэсире турында бара. Галим М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал, Г. Ибраһимов кебек өлкән буын әдипләрнең генә яңа шартларда «әдәбиятта кайбер тарихи эз калдырырлык нәрсәләр» бирүе турында сөйли.

Гражданнар сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбиятын-

дагы күзәтүләрендә Г. Нигъмәти өлкән буынга алмаш әзерләү проблемасын куя, яшь әдипләрнең фронт шартларында үсеп чыгулары, ә инде тыныч тормышта, яңа бурычлар алып, чын язучы сыйфатында калыплашулары, зур хыяллар, оптимизм, көрәш дәрте белән рухланып, яңа эчтәлектәге әсәрләр иҗат итүгә алынулары хакында яза. Тәнкыйтьче Ш. Усманов, К. Нәҗми, Н. Баян, Г. Толымбай, А. Шамов, С. Баттал, С. Кудаш, Г. Гомәр, А. Таһиров һәм башкаларның иҗатын уңай яктан билгеләп үтә. Бу чорда да, алга таба да әдәби барышка ясаган күзәтүләрендә һәм аерым шәхесләрнең иҗатларына бәяләмәләрендә Г. Нигъмәти аларның идеологик позициясен ачыклауны һәм каләм сәнгатилеген үзәккә куя. Тәнкыйтендә чорның әйдәп баручы әдибе булган Г. Ибраһимов прозасын һәм М. Горький иҗатын яктырту зур урын алып тору галимнең фәнни эзләнүләрендә әдәбияттагы уңай күренешләрне калкуландыру, алга таба яшәргә, көчәергә тиешлекләрен раслау максаты белән эш йөрткәнлеген күрсәтә. Әйтик, Г. Нигъмәти «Галимҗан Ибраһимовның әдәби хезмәтенең егерме елы» (1928) мәкаләсендә каләм иясенең иҗат эволюциясен күздән кичерә һәм эшчәнлегенең татар әдәбияты өчен кыйммәтен маһир язылган революцион эчтәлекле әсәрләр белән бәяләүндә таба.

Г. Нигъмәти «Г.Ибраһимов әсәрләрендә революция мотивлары» (1928), «Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгәниләр биргән?» (1929), «Галимҗан Ибраһимовның яңа әсәре» (1929), «Г. Ибраһимов һәм аның иҗат юлы турында» (1932) һәм башка хезмәтләрендә тәнкыйтьче Г. Ибраһимов хезмәтләрен яңа заман идеологиясенә җавап бирү, иҗат методлары, стиль үзенчәлекләре яссылыкларында бәяли. «Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгә ниләр биргән?» язмасында галим әдипнең 1909–1913 елларда дөнья күргән «Казакъ кызы», «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрләре һәм берничә эрелеваклы хикәясе турында сүз алып бара. Ул роман белән повестька инкыйлабтан соң кайбер үзгәрешләр кертелгәнлек, аларның, беренче чиратта, әдәби материал белән композициягә каравы турында әйтә, чагыштырма-типологик анализ кулланып, «коммунист әдип каләме» барлыкка китергән башка аерымлыкларны да таба. Г. Нигъмәти «Татар хатыны ниләр күрми»нең тәүге вариантын чор вазгыятенә мөнәсәбәттә ача, әсәр язылганда «татар әдәбиятында өстенлек кылган стиль, агым романтизм мотивлары, романтизм фикер тойгылары белән сугарылган иде», болар Г.Ибраһимов иҗатында да чагылды, дип белдерә һәм әлеге «тойгыларның характерлы күрсәтелеше»нә мисал рәвешендә «Диңгездә» хикәясен китерә.

Нинди генә иҗатны анализласа да, Г. Нигъмәти даими рәвештә укучыны әдәбиятка кагылышлы теоретик белемнәр белән коралландыра, һәм галимнең тәнкыйть язмалары аның теге яки бу терминга нинди эчтәлек салуын, әдәби барыштагы теге яки бу күренешләргә

мөнәсәбәтен дә ачык күрсәтеп тора. Г. Нигъмәти бу хезмәтендә, Г. Плеханов фикерләренә таянып, узган чорларда мәдәни сыйныфларның үзләреннән артта калучы төркемнәргә йогынты ясарга мөмкинлеген әйтә. Ул элеккеге әдәбиятта дворяннар тудырган романтизмны реакцион тармак дип билгели, «яңа сыйныф»ларныкын бераз революцион мотивларны да үз эченә алган романтизм дип атый, һәм Г. Ибраһимовның язу стилен шуларның икенчесенә кертә: «Г. Ибраһимовның әсәрләрендәге романтизм, реакциячел сыйныф романтизмы түгел, бәлки бөек борылыш еллары дулкыны эченә кереп тә, монда ныклап көрәш алып бару батырлыгына ирешә алмаган, шулай да бер як читтә битараф кала да алмаган иҗтимагый төркемнәр карашын күрсәтә торган романтизмнан гыйбарәт». «Г. Ибраһимовның бу әсәрләре үткәнгә – феодализм заманнарына кайтмыйлар, ул момент әдип иҗатында төп сыйфат түгел, ләкин боларда тормыш гармониясен авылдан, табигатьтән /.../ эзләү омтылышы ярылып ята. Боларда билгесез формадагы тормышка омтылыш, шуның турында сагыш бар, шуның белән бергә, һәрбер әсәрдә диярлек кызыл җеп булып сузылган "сукыр тәкъдир" көченә ышанучанлык, шуңа рәнҗүчәнлек бар» [Нигъмәти, 1958, б. 58–59, 62], – дип тә билдерә.

Г. Нигъмәтинең «Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгә ниләр биргән?» мәкаләсендә язучы прозасында чагылыш тапкан әдәби дөньяның төп үзенчәлекләренә игътибар бирелә, аның төрле тип каһарманнардан, әлеге геройларның эш-хәрәкәтләреннән, табигать сурәтләреннән, тормыш-көнкүреш картиналарыннан, гореф-гадәтләреннән, рухи дөньяларыннан, ягъни этнографик тасвирлардан да торганлыгы күрсәтелә. Галим аларны тудыру алымнары, әйтик, психологик янәшәлекләр, символлар куллану, төрле стилистик элементлар турында сүз алып бара.

Г. Нигъмәти «Г.Ибраһимов һәм аның әдәби иҗат юлы» мәкаләсен әдипнең инкыйлабкача иҗатын бәяләүдән башлый һәм шул чор әсәрләрендә аның нинди иҗтимагый катламнар тормышына игътибар иткәнлеген күрсәтә. Ул Г. Ибраһимов инкыйлабкача «Иҗтимагый һәм шәхси мотивлар аралашып йөрү белән берлектә, аның иҗтимагый мотивлары шушы революция һәм реакция дәверләренең буржуа һәм бигрәк тә вак буржуа укымышлылары хәрәкәтенә каратылганнар», «романтизм буявына» сугарылганнар иде, дигән гомумиләштерүләр ясый, «әдипнең бу дәвер әсәрләре арасында иң зур урынны» «Яшь йөрәкләр» белән «Безнең көннәр» алганны күрсәтеп бирә [Нигъмәти, 1958, б. 73–75]. Галим анализында төп игътибар «шәхес сурәтләре»нә һәм әсәрләрнең композиция белән стилистикасына юнәлтелә.

Г. Нигъмәти ике унъеллык чигендә бастырган кайбер язмаларында әдипнең язу калыбын сыйнфый көрәш тарихы белән бик тыгыз бәйли. Аның «"Безнең көннәр" һәм аның стилендә бишенче еллар сыйнфый

көрәшенең чагылышы» (1932) мәкаләсендә: «“Безнең көннәр” революцион партия һәм аның көрәшчеләре бурычларын ничек итеп аңлата, революциянең төп этәрүче көчләре дип кемнәрне ала, гомумән анда 1905 ел революциясе кайсы ягы белән һәм ничек чагылдырыла, менә бу сорауларга ничек җавап бирелүгә карап, әсәрнең сыйнфый йөзе, әдипнең нинди әдәби идеология үткәргәнлеге билгеләнәләр» [Нигъмәти, 1958, б. 97], – дигән юллар бар. Галим алга таба шул сорауларга җавап эзли, таба һәм түбәндәге гомуми нәтиҗәгә килә: «Әсәр буржуаз демократик революция сызыгында тора» [Нигъмәти, 1958, б. 119]. «Кызыл чәчәкләр»дә (1928) исә ул шул исемдәге әсәрне революциянең «төпке катлауларга» тәэсирен күрсәткән уңышлы хезмәт рәвешендә атый.

Г. Нигъмәти, әдәбиятта тоткан урынына карамыйча, теләсә кайсы язучы каләменә хас җитешсезлекләрне күрсәтеп бирергә тырыша. Г.Ибраһимов иҗатына бәйле рәвештә дә, ул теге яки бу кимчелекләрне атап килә. «Галимҗан Ибраһимовның яңа әсәре» (1928) мәкаләсендә тәнкыйтьче «Тирән тамырлар»га хас түбәндәге җитешсезлекләрне билгели: «Кайбер каһарманнар турында үтә нечкәләп җентекләү әсәрне суза, төп фикерне таркауландыра төшә. Әсәр барышы өчен кирәксез яки башкача итеп үзгәртелүе артык булган урыннар да юк түгел». Дөрес, шуның артыннан ук галим: «Ләкин бу җитешсезлекләр әсәрнең яңалыгы, көчлелеге алдында артка чигенеп калалар», – дип белдерә [Нигъмәти, 1958, б. 144–145].

Г. Нигъмәти тәнкыйтендә һәрбер каләм иясенең язганнары иҗтимагый һәм әдәби шартлар җирлегендә яктыртыла. «Гафур Коләхмәтов һәм аның иҗаты» мәкаләсендә сүз «бишенче ел дулкыннарында кайнап, татар социал-демократ большевиклары – “уралчылар” арасында яшәгән әдип» [Нигъмәти, 1958, б. 7] һәм аның төрле «сыйныф һәм иҗтимагый төркемнәрнең иҗтимагый хәрәкәтләре әйләнәсе эчендә» үскән иҗаты турында барса, «Шәриф Камал – драматург»та төп игътибарны нинди чор, нинди катлау, социаль төркемнәр тормышын кайсы материал һәм ысуллар ярдәмендә яктыртуга юнәлтелә. «Акчарлаклар»га мөнәсәбәттә, Г. Нигъмәти болай дип белдерә: «Бу комедия үзенең тематик юнәлеше, сурәтләренең бирелеше буенча, шуңа кадәр булган татар буржуа драматургиясе әсәрләреннән нигезендә аерылмый» [Нигъмәти, 1958, б. 149].

Г. Нигъмәти «Кави Нәҗми һәм хикәяләре» (1929) хезмәтендә әдип иҗатының тематик киңлекләрен, сурәтләү алымнарын, аларны куллану юлларын ача, ул тудырган сурәтләрнең төрлелеге, хәрәкәтчәнлеге, абстракттан конкретка күчеше, тасвирлар кыйммәтендә дәрәҗәлек, доминанталык хакында сүз йөртә. Хезмәттә эстетик категорияләр, тойгылар, аларның нәрсәгә хезмәт итүе хакында да фикер бар. Г. Нигъмәтигә, кайсы әдип турында гына язса да, оптимизмы дәрәҗәсен билгеләү бик мөһим. К. Нәҗминең эчке рухиятен ул, прозасы

белән бәйлелектә ачып: «Көрәш, революция тормышын язуда ул күбесенчә оптимист булса да, тыныч тормыш дәверен язуга күчкәндә инде ул, ничектер, бераз пессимизмга төшә. Белмим, ул элекке коммунизм дәверләрен сагына, белмим инде, болай сагынмаса да, яңа тыныч тормыш заманында яңа тормыш (быт) төзелешенең уңышлы чыгуына ышанмый. Ни булса булсын, аның соңгы әсәрләрендә пессимистлык күбрәк сизелә» [Нигъмәти, 1958, б. 197], – ди. Галимнең башка каләм ияләренә бәяләрендә дә аларның эчке сынуларын яки рухи күтәренлеклекләрен, чор атмосферасын чагылдырган урыннар шактый. К. Нәҗминең, Г. Нигъмәти билгеләгәнчә, инкыйлабтан соң бераз вакыт узуга, өметсез язуы, тормышның караңгы якларына күбрәк игътибар бирүе, уңай типлар бирә алмавы, агитацияләренең кайчак шәрә тудырылуы, текст тукымасына отышлы үтеп керә алмавы әдип күңелендә барган катлаулы кичерешләр хакында да сөйли, дип уйларга кирәк.

Г. Нигъмәти әдәби әсәрләрдә буржуа тормышын тәнкыйть итү, аңа меңнәрне ымсындырган һәм барлык милләтләр өчен уртак Яңаны каршы кую проблемасын бервакытта да читләп узмаска тырыша. Ул «Татар совет театр һәм драматургиясенең үсеше» хезмәтендә болай дип яза: «Әсәрләре соңгы унбиш ел эчендә татар театры репертуарыннан төшми килгән К. Тинчурин революциягә хәтле үк татар буржуа, мещан тормышын тәнкыйть итеп чыккан иде. Ләкин ул вакытта әле аның әсәрләре милләтчелек карашлары белән сугарылып язылган иделәр. Октябрьдән соң ул каләмен пролетариат революциясенә хезмәт иттерүгә бора һәм 1927 елда татар буржуазиясенең контрреволюцион асылын ачып биргән сатирик комедиясе “Җилкәнсез”не бирә. Шуннан соң “Ил”, “Зәңгәр шәл” музыкалы пьесаларында беркадәр милли демократчылык карашларын чагылдырып чыккан бу язучы 1932 елда Татарстан колхозлары тормышыннан алынган “Кандыр буе”н, социалистик төзелеш гигантларының эшкә җибәрелеш чорларында күрелгән авырулар һәм аларның ничек бетерелүен күрсәткән һәм бездә завод-фабрикаларда ничек итеп яңа кешеләр җитештерелүен сурәтләндергән “Тургай” пьесасын /.../ яза» [Нигъмәти, 2011, б. 325]. Г. Нигъмәти, беррәттән, «хроникаль пьесаларга хас җитешсезлекләр»не – характерларның тулы эшләнмәвен, эпизодиклыкны, кайбер шәхесләрне бирүдә схематизм кебек күренешләрне дә атап уза.

Г. Нигъмәти тәнкыйтендә үзәктә торган проблемаларның берсе – яңа әдәбиятта уңай герой мәсьәләсе. Әлбәттә, уңай герой дигәндә, галим зур хыяллар белән янган, дошман элементлардан һәр яктан караганда да өстенрәк торган социалистик төзелешләр кешесен күз алдында тота. Аның күренекле иҗатлардан заманчалык рухын, чор кешесен, тормышчан тасвирларны эзләве Г. Толымбай прозасына бәяләмәләрендә бик ачык күренә. Г. Нигъмәти әдипнең 1920 елларның икенче яртысында ба-

сылган әсәрләрендә гади авыл кешеләре һәм аларның көндәлек тормышы тасвирлануга игътибар итә һәм болай дип яза: «Толымбай, /.../ әдәбият әсәре үзенең мөндәриҗәсен тормыштан алырга тиешлеген күз алдында тотып, үзе яза торган тормыш күренешләрен һәрвакыт өйрәнә килде» [Нигъмәти, 1929, б. 40].

Г. Нигъмәтинең узган гасырның егерменче-утызынчы елларында Тукай фәнен үстерүгә керткән өлеше бинаһая зур: ул шагыйрь иҗатын гыйльми яктыртуны яңа көч белән җанландыра, Тукайның фәнни биографиясен төзү, аны яңа фактлар белән баету юнәлешендә эшли; иҗатын комплекслы анализлау, пропагандалау кебек гамәлләр башкара. Әле әдәбият мәйданына узып кына барган чорында ук Г. Нигъмәти Г. Тукай иҗатының социаль җирлеген ачкан «Габдулла Тукаев» (1923) мәкаләсен язган була. Алга таба галимнең «Шагыйрь Габдулла Тукай үлүгә 15 ел тулды» (1928) хезмәтендә Тукай поэзиясенә хас тема-мотивлар шулай ук авторның шәхси тормышы, социаль хәле белән бәйләнештә карала. Г. Нигъмәтинең гыйльми тирәлектәге абруе сәбәпле дә, Тукай мирасының идея-эстетик бәһасе башка галимнәр тарафыннан озак еллар дәвамында социологик принциптан чыгып бәяләнүен дәвам итә. Г. Нигъмәтинең шагыйрь иҗатын әдәби багланышлар кысасында анализлавы Тукай гыйльмиятендәге шул юнәлешне көчәйтеп җибәрүгә һәм хәтта бүгенгә кадәр китереп җиткерүгә хезмәт итә. Г. Нигъмәти Тукайның әдәби үсеш этапларын күзаллатырлык фикерләр әйтә, шигъри иҗеге турында дәлилле сүз алып бара, шагыйрь кулланган тезмә сүз системаларын, ритм, рифма, строфика һәм композиция үзенчәлекләрен дөрес тотып ала. Димәк, Тукай иҗатының идея эчтәлеген форма белән тыгыз бәйләнештә ача, шигырьләренең сурәтлелек дәрәҗәсенә зур игътибар бирә.

Г. Нигъмәти халык авыз иҗатының Тукайга тәэсирен, шагыйрьнең тәрҗемәчелек һәм публицистик осталыгын ача. Галим Тукай каләменең көчле ягы сатирада икәнлекне, аның тормышның кайсы якларына юнәлдерелгәнлеген оста тотып ала. Шунысы мөһим: Г. Нигъмәти һәрвакыт Тукай мирасын комплекслы өйрәнү кирәклеген аңлап эш йөртә. «Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы» (1936) мәкаләсендә, мәсәлән, галим Тукай поэзиясен фольклор, башка халыклар әдәбияты тәэсире планында да, шәхси үзенчәлекләрен ачыклау юнәлешендә дә анализлый. Әлеге хезмәттә ул Тукай сатирасының заманчалыгын, оперативлыгын, тәнкыйть объектының тәгаенлеген һәм ысул-чараларын билгели, «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш» (1908) поэмасын исә югары дәрәҗәдәге сатира үрнәге буларак характерлый, лирикасына хас үзенчәлекләрне барлый, һәм, гомумән алганда, иҗатын үсешүзгәрештә күрсәтә. Социологик мәктәп вәкиле булган Г. Нигъмәти фәнни язмаларында башта Тукайны вак буржуа шагыйре дигән карашны уздыра, чөнки узган әдәбиятка, тулаем алганда да, шул ракурстан карый. Заман

өчен актуальлеген аңлаган галим шагыйрь иҗатының, беренче чиратта, иҗтимагый-социаль ягын яктыртуга игътибар бирә, шунлыктан да сатирасын ныграк калкуландыра, ә инде интим лирикасына дикъкать итми диярлек. Г. Нигъмәти Тукайның милли-дини хисләрен, бигрәк тә Толстойдан килгән карашларын, дөньяны аңлауда чикләнгәнлеге дип карап, кире кага. Тора-бара ул Тукай мирасын бәяләүдәге ялгышлардан әкренләп читкә китә.

Һ.Такташ, Х.Туфан кебек яшь һәм талантлы язучылар иҗатын анализлаганда, Г. Нигъмәти шулай ук әсәрләренең актуальлеге һәм форма камиллеге мәсьәләләренә игътибар итә. Ул, Һ.Такташка бәйле рәвештә, болай дип белдерә: «...аның тормыштагы актуаль мәсьәләләргә җавап бирергә тырышып караулары да булмады түгел. Мәсәлән, аның “Мәхәббәт тәүбәсе” шундый әсәрләрдән булып, художество ягыннан да нык игътибарга алынырга тиешле әсәр» [Нигъмәти, 1927, б. 30]. Г. Нигъмәти «Һади Такташ» (1932) язмасын шагыйрь иҗатының борылышларын тасвирлаудан башлый: «Такташның Октябрь елларында революциягә юлаучылыктан пролетариат әдәбиятына союздашлыкка таба үсеше аның символист-идеалистлыктан Советлар илендәге бүгенге социализм төзелешенең кызу темпта югарыга барган күренешләрен шигъри сурәтләрдә күрсәтү һәм тәгъбир итүгә килеп ялгану рәвешендә барды. 1916 елда ук берничә шигырь язып та, шагыйрьлек эшчәнлеген чыннан тик Октябрьдән соң гына башлаган Такташның үсешендәге югарыда әйтелгәнчә булган борылышны күзәтү вак буржуа катлавыннан чыккан һәм шуның карашыннан килгән бер интеллигентның сәяси-әдәби үзгәрүе нинди катлаулы юллар белән баруын, шагыйрьдә пролетариатка чит карашлар революция тәрбиясе аркасында ничек җимерелеп, ватылып ташлана килүен безгә кызык мисаллар бирә алыр» [Нигъмәти, 1958, б. 164].

Аталган хезмәттә Һ.Такташның иҗат юлы этапларга бүленә, һәр баскычта каләменә хас сыйфатлар, шагыйрь тудырган символик сурәтләрнең җирлеге һәм эчтәлеге, әсәрләренең кайсы сыйныфка хезмәт итүе ачыклана. Чор модасына бирелеп, Г. Нигъмәти ул кулланган методларның, аерым алганда символизмның реакционмы, әллә прогрессив юнәлештәгесеме икәнлеге турында сүз йөртә, пролетариат диктатурасын урнаштыруга, ныгытуга юнәлтелгән сәяси-иҗтимагый көрәшләр чорында «абсолют рәвештәге шәхси азатлык өчен кычкырып чыгу революция өчен» [Нигъмәти, 1958, б. 170] кирәксез иде, дигән карашны уздыра. Г. Нигъмәти тәнкыйтендә чагыштырма-типологик анализга зур урын бирелә, Һ. Такташ поэзиясе С. Рәмиев, Г. Тукай һәм башкалар иҗаты янәшәсенә куеп карала. Галим, Такташ әсәрләренең тормышчанлык дәрәҗәсен, реаль эчтәлеген ачканда, марксизм-ленинизм тәгълиматына, марксистларның, әдәбият – идеологик күренеш, өскорма күренеш, дигән сүзләренә, «вак

буржуаз стихия» турында фикер йөртүләренә таяна. Ул, Такташның 1918–1922 еллардагы әсәрләреннән чыгып: «Чыннан да, Такташ бу шигырьләрендә революция вакытында теге яки бу сыйныфның иҗтимагый, икътисади програмасын төшенү, үзләштерүдән ерак тора әле.

Ул һаман үзен сыйныфтан тыш торучы һәм үзе дә рәтләп төшенмәгән миссияне үтәүче "яшь пигамбәр" итеп күрә. Ләкин аның барып таяныр иҗтимагый катлавы юк» [Нигъмәти, 1958, б. 173], – дип белдерә. Г. Нигъмәти Такташ әсәрләрендә тормышны тәгаенрәк сурәтләү омтылышы 1923 елдан көчәя төшә дип саный, әмма Такташның әле яңа этап башында да инкыйлаб бурычларын ахыргача аңлый алмавын күрсәтә.

«Һади Такташ»та Г. Нигъмәти егерменче еллар ахырында башланган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрне, аның мәдәният һәм әдәбиятта чагылышын шактый төгәл күрсәтә, әмма Яңа өчен кискен көрәшне яклап сүз алып бара, иң кирәкле дип санаган урында тагын коммунистлар тәгълиматына, бу очракта Сталин сүзләренә таяна, ул тәнкыйть иткән «тигезлек» теориясенең өлешчә Такташ иҗатында да чагылуын, аның да еш кына «партиясез» әдәбият карашларын уздыруын сөйли. Шагыйрь иҗатындагы уңай күренешләр рәвешендә аның «революция барлыгына күз сала» башлавын, аның үсеп баруын, яңа көчләр тудыруын күрүен, индивидуалистлыкны коллективка буйсындыру омтылышының көчәюен атый. Мәкалә ахырында Г. Нигъмәти Такташ иҗатының соңгы этабы хакында мондый фикерләр әйтә: «...31 елда инде аның алдында бөтен төзүчелек һәм бәхет китерүчелек көче белән пролетариатның сыйнфый көче килеп баса /.../, сыйныф ничек итеп төзү эшләре алып барганын, сыйныф һәм аның әгъзалары арасында мөнәсәбәт берлекле булганын, аерым аңлы әгъзаларның "шәхси" бәхете сыйныф бәхете булганын, шуңа күрә дә болар арасында каршылык булмаганын күрә башлый» [Нигъмәти, 1958, б. 184–185].

Г. Нигъмәти 1936 елда шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында «Һ.Такташ» исемле тагын бер мәкалә чыгара. Ул анда яңадан бер кат Һ.Такташ поэзиясенең «вак буржуаз бунтарьлыктан башлап, пролетариат революциясе тудырган чынбарлыкны дөрес төшенергә һәм шуның тормышта аерым чагылышларын күрсәтергә тырышу аша үтеп, социалистик реконструкция эпохасының бай җимешләрен, социализм иленең гөрләп чәчәк атуы һәм анда яңа кешеләр, күп санда геройлар туа баруын күрсәтүгә килеп җитүе» [Нигъмәти, 1958, б. 186] турында яза. Мәкалә шагыйрь әсәрләренең халык арасында үтә популярлыгы сәбәпләрен күрсәтү белән тәмамлана.

Г. Нигъмәти югары бәя биргән шагыйрьләрнең чираттагысы – Хәсән Туфан. Ул аның хакында фәнни эзләнүләрне 1927 елда «Нәни разбойниклык, хатынсыз ай һәм бераз гына мужик фәлсәфәсе турында» дигән мәкалә язу белән башлый. Алга таба тәнкыйтьче шагыйрь иҗатын теге

яки бу күләмдә «Туфан шигырьләрендә производство мотивлары» (1928), «Туфан шигырьләре» («Революция елларындагы әдәбиятыбыз». М., 1929), «Матур әдәбият фронтында ун ел» («Ун ел эчендә татар матур әдәбияты». Казан, 1930), «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (1933), «Социалистик реконструкция чорында татар совет матур әдәбияты» (1934) дигән тәнкыйть хезмәтләрендә чагылдыра.

Г. Нигъмәти «Туфан шигырьләре» (1929) язмасында каләм иясен: «башлап «производство» мотивларын көйләп чыккан шагыйрь» [Нигъмәти, 1958, б. 202],– дип атый, хезмәт темасына нисбәтле Туфан тудырган сурәтләрнең «җансыз завод көчен күрсәткән, механика көчен генә әйтергә теләгән сурәтләр түгел»леген, Х. Туфанның һәм эчтәлек, һәм форма ноктасыннан камиллеккә омтылуын әйтә. Г. Нигъмәти татар әдәбиятында эшчеләр тормышын чагылдырган әсәрләр авторларының производство темасын белмәүләрен күрсәтә. Аның фикеренчә, шул тормыштан чыкканнар аны сәнгати югарылыкта тасвирлый алмый, бары тик әдәби әзерлекле язучылар үстерү генә әлеге проблеманы уңышлы хәл итәчәк. Ул Х. Туфанны эшчеләр тормышын яхшы белүче, производство мотивларына сәнгати югарылыктагы әсәрләр иҗат итүгә дә сәләтле дип саный. Г. Нигъмәти Туфанның эзләнүчәнлек сыйфатын, яңа сурәт һәм ифадәләр табарга тырышуын, әсәрләренең тел-сурәтләү ноктасыннан байлыгын мактый, шәхси рухи кичерешләрне бирүгә караганда, күпчелекнең уй-хисләрен тасвирлауга өстенлек бирүен, иҗатында «сөйләү һәм декламация тибындагы лирика» [Нигъмәти, 1958, б. 214] зур урын тотуын күрсәтә.

* * *

Г. Нигъмәти XX гасырның егерменче-утызынчы елларында татар совет әдәбиятының методологик нигезләрен эшләүгә зур өлеш керткән, сүз сәнгатенә заман алып килгән үзгәрешләргә игътибарлы галимнәрнең берсе иде. Аның тәнкыйтендә, теге яки бу иҗатның идеялелеге, кайсы сыйныфка хезмәт итүе, заманчалыгы, тормышчанлыгы, типлары һәм уңай геройлары кебек проблемаларны чишү янәшәсендә, язучылар кулланган әдәби алым-чараларны, әсәрләренең сәнгатилек дәрәҗәсен, каләм көчен ачыклау да читтә калмады. Г. Нигъмәти талант иясенең дөнья сүз сәнгатендәге уңай традицияләрдә калыплашкан камил шәхси стилгә ия булуын, ә язганнарының социалистик төзелешләргә хезмәт итүен яклады. Аның егерменче-утызынчы еллардагы тәнкыйте, бер яктан, әдәби әсәрләрне бәяләүдә норматив система булдыруга хезмәт итсә, икенче яктан, талантның индивидуаль чагылышка ияләгән дә раслады.

**Әдәбият**

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

*Нигъмәти Г.* Революция елларындагы әдәбиятыбыз. М.: СССР халыкларының үзәк нәшр., 1929.

*Нигъмәти Г.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.

*Нигъмәти Г.* Татар совет театр һәм драматургиясенең үсеше // Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз.: И. Һадиев, Р. Батулла. Казан: Җыен, 2011. Б. 325.

*Нигъмәти Г.* Ун ел эчендә безнең әдәбиятыбыз // Безнең юл. 1927. № 10.

***Харрасова Рифә Фатхрахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*